ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06.06.2019 Алексеевск ш.т.б № 28

**«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном учреждениесенең «Иң яхшы табиб» «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында**

Һөнәри камиллеккә, нәтиҗәле хезмәткә, сәламәтлек саклау белгечләре өчен нәтиҗәле хезмәт оештыру һәм өстәмә стимуллар булдыру, медицина хезмәткәренең абруен үстерү, аларның иҗтимагый әһәмиятен арттыру максатларында

**карар бирәм:**

1. «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном учреждениесенең «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы нигезләмәләрне расларга (Кушымта №1, №2, №3).
2. Финанс-бюджет палатасына (Леденцов О.Н.) приз фонды сыйфатында 100 000 сум күләмендә акча бүлеп бирергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**

Алексеевск районы
Башлыгының
06.06.2019 № 28 карарына
1нче кушымта

# АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫНЫҢ «АЛЕКСЕЕВСК ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ «ИҢ ЯХШЫ ТАБИБ» МУНИЦАИПАЛЬ ГРАНТЫН БИРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

Максат: Һөнәри камиллеккә, нәтиҗәле хезмәткә, сәламәтлек саклау белгечләре өчен нәтиҗәле хезмәт оештыру һәм өстәмә стимуллар булдыру. Табибларның абруен үстерү, аларның иҗтимагый әһәмиятен арттыру.

Бурычлар: Югары һөнәри осталык һәм эшне нәтиҗәле оештыру өчен җиңүчеләрне бүләкләү. Иң яхшы белгечләрнең казанышларын, аларның тармакта, район халкы арасында алдынгы тәҗрибәсен пропагандалау, медицина хезмәткәре имиджын формалаштыру, аның хезмәтендәге җаваплылыкны һәм әһәмиятен формалаштыру.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы башлыгы гранты белән «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең иң яхшы табибы югары һөнәри осталыгы һәм Алексеевск районында сәламәтлекне саклау эшенә керткән өлеше өчен бүләкләнә.
1.2. Ел саен «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы табиб» номинациясе буенча район башлыгының 40.0 мең сум күләмендә гранты түләнә. Бәйге барлык белгечлекләр буенча, табиблар арасында үткәрелә.
1.3. Район башлыгы гранты бәйге нәтиҗәләре буенча сайлап алу узган табибка бирелә.
1.4. Табиб район Башлыгы грантын яңадан алу хокукына белгечлеге буенча эш стажы 5 елдан да иртәрәк булмаган срокта ия була.
1.5. Район башлыгы грантын бирү өчен табиб сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.
1.6. Башлык гранты Алексеевск районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс чараларыннан түләнә һәм табибларының һөнәри һәм квалификацион үсешен стимуллаштыру, абруйларын үстерү өчен билгеләнгән.

## 2. Бәйгенең сайлап алу критерийлары

Иң яхшы табибны сайлап алу ике төркем критерийлар нигезендә башкарыла: квалификацон сайлап алу һәм бәйгенең сайлап алу критерийлары.

Катнашу һәм сайлап алу критерийлары теркәлгән һәм мәҗбүри булып тора.

2.1.Катнашу критерийлары:

- табибның белгеч сертификаты булу;
- табиб беренче яки югары квалификацион категориягә ия;
- хезмәт эшчәнлегенең характеристикасы;
- «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә табибның эш стажы 3 елдан ким түгел.

2.2.Сайлап алу критерияләре:

2.2.1: Сыйфат параметрлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- соңгы өч ел эчендә статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдыручы һөнәри эшчәнлекнең төп нәтиҗәләре турында мәгълүматлар – 5 балл;

- соңгы өч ел эчендә бәйгедә катнашучы тарафыннан (яки ул турыдан-туры катнашында) профилактика, диагностика һәм дәвалауның яңа ысулларын булдыру яки гамәлгә кертү – 2 балл;

- профилактик эш, халыкка гигиена белеме бирү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләре булу – 2 балл;

- иҗтимагый бәяләү, пациентларның табиб турында фикере – 1 балл.

## 3. Бәйгенең сайлап алуларын үткәрү тәртибе

3.1.Иң яхшы табибны бәйге нигезендә сайлап алуны үткәрү максатында бәйге комиссиясе раслана.

3.2.Бәйгедә катнашу өчен дәгъва кылучылар комиссия рәисе исеменә гариза юллыйлар.

3.3.Бәйгедә катнашу өчен гаризалар агымдагы елның 15 маеннан да соңга калмыйча тапшырылырга тиеш.

3.4.Грант алуга гарианың титул битендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- табибның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
- бәйгенең номинациясе;
- гаризаны бирү датасы;
- табибның имзасы.

3.5.Документлар муниципаль бәйге комиссиясенә исемлек нигезендә тапшырыла:

- бәйгедә катнашу өчен Комиссия рәисе исеменә гариза;
- белгечлек турында диплом күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;
- хезмәт кенәгәсе күчермәсе;
- әлеге Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә соңгы өч елдагы эшчәнлегенә анализ;
- булган бүләкләре.

Документлар, карау һәм өйрәнү өчен уңайлы булсын өчен, файллы папкаларга җыелган булырга тиеш.

## 4. Бәйгедә җиңүчене сайлап алу

4.1.Бәйгедә җиңүчене сайлап алуны үткәрү Комиссия компетенциясенә керә.

Алексеевск муниципаль районы башлыгы грантын алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу буенча бәйге комиссиясе составы:

1. Кадыров Н.К. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе,
2. Фахрутдинов И.А. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы – комиссия рәисе урынбасары,
3. Гусева Н.Н. – медицина бүлеге буенча баш табиб урынбасары,
4. Фасахова А.Р. – клиник-экспертиза эше буенча баш табиб урынбасары,
5. Аляшева И.Г. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең төп шәфкать туташы
6. Гордеева Т.Г. – АМКның өлкән фельдшеры – комиссия сәркатибе,
7. Валеева З.Н. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең профком рәисе.

4.2.Сайлап алу критерийлары буенча дәгъвачыларның Документлар пакетына теркәү һәм техник экспертизаны Комиссия агымдагы елның 1 июненә кадәр үткәрә.

4.3.Комиссия карары буенча табиб эшчәнлегенә эксперт бәя бирү турыдан-туры аның эш урынына барып гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4.4.Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре нигезендә Комиссия претендентлар рейтингын төзи, башлык грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм Алексеевск муниципаль районы башлыгына карау нәтиҗәләрен бирә.

4.5.Грант бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

4.6.«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы табиб» грантын тапшыру ел саен агымдагы елның июнь аенда Медицина хезмәткәрләре көненә багышланган тантаналы утырышта Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан башкарыла.

4.7.Бәйге нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һәм башкалар аша киң җәмәгатьчелек игътибарына мәҗбүри рәвештә җиткерелә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**

Алексеевск районы
Башлыгының
06.06.2019 № 28 карарына
2 нче кушымта

# АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫНЫҢ «АЛЕКСЕЕВСК ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ « ИҢ ЯХШЫ УРТА МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТКӘРЕ» МУНИЦАИПАЛЬ ГРАНТЫН БИРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы башлыгы гранты белән «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең иң яхшы урта медицина хезмәткәре югары һөнәри осталыгы һәм Алексеевск районында сәламәтлекне саклау эшенә керткән өлеше өчен бүләкләнә.

1.2. Ел саен 30.0 мең сум күләмендә 1 грант түләнә.

1.3. Район башлыгы гранты бәйге нәтиҗәләре буенча сайлап алу узган муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесенең урта медицина хезмәткәренә бирелә.

1.4. Урта медицина хезмәткәре район Башлыгы грантын яңадан алу хокукына 5 елдан да иртәрәк булмаган срокта ия буа.

1.5. Район башлыгы грантын бирү өчен урта медицина хезмәткәре сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

1.6. Башлык гранты Алексеевск районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс чараларыннан түләнә һәм урта медицина хезмәткәренең һөнәри һәм квалификацион үсешен стимуллаштыру өчен билгеләнгән.

## 2. Бәйгене үткәрү шарты һәм тәртибе

2.1. Бәйге сайлап алуларын үткәрү максаты бәйге комиссиясе тарафыннан раслана.

2.2. «Шәфкать туташы эше», «Дәвалау эше» һәм «Акушерлык эше» белгечлекләре буенча бәйгедә катнашу өчен урта медицина белеме, беренче яки югары квалификация категориясе, белгечлек буенча 3 елдан да ким булмаган эш стажы булган «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең белгечләре алына.

2.3. Бәйгегә тәкъдим итү, «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» исеменә дәгъва итүчеләрнең һөнәри, иҗади, әхлакый сыйфатларыннан чыгып, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең аерымланган бүлекчәләре коллективлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Дәгъвачыларның документлары гариза бирүче тарафыннан муниципаль бәйге комиссиясенә агымдагы елның 15 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла:

- бәйгедә катнашу өчен Комиссия рәисе исеменә гариза;
- белгечлек турында диплом күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;
- хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

2.5. Грант алуга гаризаның титул битендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- аерымланган бүлекчәнең исеме;
- урта медицина хезмәткәренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
- бәйгенең номинациясе;
- гаризаны бирү датасы;
- баш табибның имзасы.

2.6. Бәйгене үткәрү датасын комиссия билгели.

Алексеевск муниципаль районы башлыгы грантын алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу буенча бәйге комиссиясе составы:

1. Кадыров Н.К. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе,
2. Фахрутдинов И.А. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы – комиссия рәисе урынбасары,
3. Гусева Н.Н. – медицина бүлеге буенча баш табиб урынбасары,
4. Фасахова А.Р. – клиник-экспертиза эше буенча баш табиб урынбасары,
5. Аляшева И.Г. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең төп шәфкать туташы
6. Гордеева Т.Г. – АМКның өлкән фельдшеры – комиссия сәркатибе,
7. Валеева З.Н. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең профком рәисе.

2.7. Сайлап алу критерийлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- бәйгедә катнашучыларның соңгы өч ел эчендә статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдыручы һөнәри эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре, медицина технологияләренә ия булулары турында хисабы – 5 балл;
- бәйгедә катнашучы эшен характерлаучы фото-видеоматериаллар – 2 балл;
- профилактик эш, халыкка гигиена белеме бирү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләре булу – 2 балл;
- иҗтимагый бәяләү, пациентларның табиб турында фикере – 1 балл.

Ике һәм аннан да күбрәк катнашучы бер үк күләмдә балл җыйса, аларга бәйгедә җиңүчене билгеләү максатында өстәмә теоретик яки гамәли биремнәр тәкъдим ителә.

2.8. Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре нигезендә Комиссия претендентлар рейтингын төзи, башлык грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм Алексеевск муниципаль районы башлыгына карау нәтиҗәләрен бирә.

2.9. Грант бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

2.10. «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» грантын тапшыру ел саен агымдагы елның июнь аенда Медицина хезмәткәре көненә багышланган тантаналы утырышта Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан башкарыла.

2.11. Бәйге нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һәм башкалар аша киң җәмәгатьчелек игътибарына мәҗбүри рәвештә җиткерелә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**

Алексеевск районы
Башлыгының
06.06.2019 № 28 карарына
3 нче кушымта

**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫНЫҢ «АЛЕКСЕЕВСК ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ» ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ «ФЕЛЬДШЕР-АКУШЕРЛЫК ПУНКТЫНЫҢ ИҢ ЯХШЫ МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТКӘРЕ» МУНИЦАИПАЛЬ ГРАНТЫН БИРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Алексеевск муниципаль районы башлыгы гранты белән «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә караган фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәре югары һөнәри осталыгы һәм Алексеевск районында сәламәтлекне саклау эшенә керткән өлеше өчен бүләкләнә.

1.2.Ел саен 30.0 мең сум күләмендә 1 грант түләнә.

1.3.Район башлыгы гранты бәйге нәтиҗәләре буенча сайлап алу узган муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесенә караган фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәренә бирелә.

1.4.Фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәре район Башлыгы грантын яңадан алу хокукына 5 елдан да иртәрәк булмаган срокта ия буа.

1.5.Район башлыгы грантын бирү өчен фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәрен сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

1.6.Башлык гранты Алексеевск районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс чараларыннан түләнә һәм фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәренең һөнәри һәм квалификацион үсешен стимуллаштыру, абруйларын үстерү өчен билгеләнгән.

2. Бәйгене үткәрү шарты һәм тәртибе

2.1. Бәйге сайлап алуларын үткәрү максаты бәйге комиссиясе тарафыннан раслана.

2.2. «Шәфкать туташы эше», «Дәвалау эше» һәм «Акушерлык эше» белгечлекләре буенча бәйгедә катнашу өчен урта медицина белеме, беренче яки югары квалификация категориясе, белгечлек буенча 3 елдан да ким булмаган эш стажы булган булган «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең фельдшер-акушерлык пунктларында эшләүче белгечләре алына.

2.3. Бәйгегә тәкъдим итү, «Иң яхшы фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәре» исеменә дәгъва итүчеләрнең һөнәри, иҗади, әхлакый

сыйфатларыннан чыгып, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең аерымланган бүлекчәләре коллективлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Дәгъвачыларның документлары гариза бирүче тарафыннан муниципаль бәйге комиссиясенә агымдагы елның 15 маеннан да соңга калмыйча тапшырыла:

- бәйгедә катнашу өчен Комиссия рәисе исеменә гариза;
- белгечлек турында диплом күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;
- хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

2.5. Грант алуга гаризаның титул битендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- аерымланган бүлекчәнең исеме;
- урта медицина хезмәткәренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме;
- бәйгенең номинациясе;
- гаризаны бирү датасы;
- баш табибның имзасы.

2.6. Бәйгене үткәрү датасын комиссия билгели.

Алексеевск муниципаль районы башлыгы грантын алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу буенча бәйге комиссиясе составы:

1. Кадыров Н.К. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе,
2. Фахрутдинов И.А. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы – комиссия рәисе урынбасары,
3. Гусева Н.Н. – медицина бүлеге буенча баш табиб урынбасары,
4. Фасахова А.Р. – клиник-экспертиза эше буенча баш табиб урынбасары,
5. Аляшева И.Г. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең төп шәфкать туташы
6. Гордеева Т.Г. – АМКның өлкән фельдшеры – комиссия сәркатибе,
7. Валеева З.Н. – «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең профком рәисе.

2.7. Сайлап алу критерийлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- бәйгедә катнашучыларның соңгы өч ел эчендә статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдыручы һөнәри эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре, медицина технологияләренә ия булулары турында хисабы – 5 балл;
- бәйгедә катнашучы эшен характерлаучы фото-видеоматериаллар – 2 балл;
- профилактик эш, халыкка гигиена белеме бирү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләре булу – 2 балл;
- иҗтимагый бәяләү, пациентларның табиб турында фикере – 1 балл.

Ике һәм аннан да күбрәк катнашучы бер үк күләмдә балл җыйса, аларга бәйгедә җиңүчене билгеләү максатында өстәмә теоретик яки гамәли биремнәр тәкъдим ителә.

2.8. Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре нигезендә Комиссия претендентлар рейтингын төзи, башлык грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм Алексеевск муниципаль районы башлыгына карау нәтиҗәләрен бирә.

2.9. Грант бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

2.10.«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы фельдшер-акушерлык пунктының медицина хезмәткәре» грантын тапшыру ел саен агымдагы елның июнь аенда Медицина хезмәткәре көненә багышланган тантаналы утырышта Алексеевск муниципаль районы башлыгы тарафыннан башкарыла.

2.11.Бәйге нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һәм башкалар аша киң җәмәгатьчелек игътибарына мәҗбүри рәвештә җиткерелә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**